**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О дополнительных мерах государственной поддержки студентов государственных образовательных организаций высшего образования, расположенных на территории Республики Татарстан»**

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 21 декабря 2010 года № УП-835 «О дополнительных мерах государственной поддержки студентов государственных образовательных организаций высшего образования, расположенных на территории Республики Татарстан» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 4 июня 2014 года № УП-522, от 27 августа 2019 года № УП-504, от 17 января 2020 года № УП-15, от 26 марта 2020 года № УП-195 и от 7 июня 2021 года № УП-454) следующие изменения:

а) в Указе:

в наименовании слово «государственных» исключить;

в преамбуле слово «государственных» исключить;

в абзаце первом пункта 1 слова «в государственных» заменить словами «по образовательным программам высшего образования – программам бакалавриата, программам специалитета, программам магистратуры за счет бюджетных ассигнований федерального бюджета, бюджета Республики Татарстан, местного бюджета, а также за счет средств физических или юридических лиц в»;

в пункте 3 слова «в государственных» заменить словами «по образовательным программам высшего образования – программам бакалавриата, программам специалитета, программам магистратуры за счет бюджетных ассигнований федерального бюджета, бюджета Республики Татарстан, местного бюджета, а также за счет средств физических или юридических лиц в»;

в пункте 6 слова «в ведущих государственных» заменить словами «по образовательным программам высшего образования – программам бакалавриата, программам специалитета, программам магистратуры за счет бюджетных ассигнований федерального бюджета, бюджета Республики Татарстан, местного бюджета, а также за счет средств физических или юридических лиц в»;

пункт 7 признать утратившим силу;

б) в Положении о стипендиях Президента Республики Татарстан для

студентов, обучающихся по очной форме обучения в государственных образовательных организациях высшего образования, расположенных на территории Республики Татарстан, из числа победителей и призеров олимпиад школьников, выпускников, набравших по 100 баллов по результатам единого государственного экзамена, а также победителей и призеров национального и мирового чемпионатов по профессиональному мастерству по стандартам WorldSkills, национального и международного чемпионатов по профессиональному мастерству среди инвалидов и лиц с ограниченными возможностями здоровья «Абилимпикс»:

в наименовании слова «в государственных» заменить словами «по образовательным программам высшего образования – программам бакалавриата, программам специалитета, программам магистратуры за счет бюджетных ассигнований федерального бюджета, бюджета Республики Татарстан, местного бюджета, а также за счет средств физических или юридических лиц в»;

в пункте 1 слова «по очной форме обучения в государственных» заменить словами «по очной форме обучения по образовательным программам высшего образования – программам бакалавриата, программам специалитета, программам магистратуры за счет бюджетных ассигнований федерального бюджета, бюджета Республики Татарстан, местного бюджета, а также за счет средств физических или юридических лиц в», слово «государственных» исключить;

пункт 2 после слов «по очной форме обучения» дополнить словами «по образовательным программам высшего образования – программам бакалавриата, программам специалитета, программам магистратуры за счет бюджетных ассигнований федерального бюджета, бюджета Республики Татарстан, местного бюджета, а также за счет средств физических или юридических лиц»;

пункт 3 изложить в следующей редакции:

«3. Назначение стипендий Президента Республики Татарстан осуществляется указом Президента Республики Татарстан ежегодно с 1 сентября на весь период обучения по образовательной программе в образовательной организации высшего образования при наличии положительных результатов освоения соответствующей образовательной программы высшего образования по итогам промежуточной или итоговой аттестации в соответствии с календарным учебным графиком (отсутствие академической задолженности и оценки «удовлетворительно»).»;

в пункте 4:

абзац первый дополнить словами «, направляемых в Министерство образования и науки Республики Татарстан не позднее 15 сентября текущего года.»;

в абзаце третьем слова «до 20 августа» заменить словами «до 1 октября»;

в пункте 8:

абзац первый изложить в следующей редакции:

«При предоставлении студенту академического отпуска, отчислении студента из образовательной организации высшего образования или переходе (переводе) его на иную образовательную программу, не соответствующую профилю олимпиады, либо в иную образовательную организацию высшего образования, не соответствующую требованиям пункта 1 настоящего Положения, либо в случае наличия у студента оценки «удовлетворительно» или академической задолженности по итогам промежуточной аттестации, либо оценок «удовлетворительно» или «неудовлетворительно» по итогам итоговой аттестации выплата стипендии Президента Республики Татарстан прекращается по решению Министерства образования и науки Республики Татарстан.»;

абзац второй после слов «выплаты стипендии» дополнить словами «Президента Республики Татарстан»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«В случае последующей ликвидации академической задолженности, успешного завершения промежуточной или итоговой аттестации, следующей за аттестацией, по итогам которой студентом были получены оценки «не зачтено», «удовлетворительно», «неудовлетворительно», выхода студента из академического отпуска выплата стипендии Президента Республики Татарстан не возобновляется.».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
26 июля 2022 года
№ УП-497

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмалары студентларына дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмалары студентларына дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2010 елның 21 декабрендәге ПУ-835 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 4 июнендәге ПУ-522 номерлы, 2019 елның 27 августындагы ПУ-504 номерлы, 2020 елның 17 гыйнварындагы ПУ-15 номерлы, 2020 елның 26 мартындагы ПУ-195 номерлы һәм 2021 елның 7 июнендәге ПУ-454 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) Указда:

атамасында «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

преамбулада «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

1 пунктның беренче абзацында «дәүләт» сүзен «федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет бюджет ассигнованиеләре, шулай ук физик һәм юридик затлар акчалары хисабына югары белем бирү мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары буенча» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «дәүләт» сүзен «федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет бюджет ассигнованиеләре, шулай ук физик һәм юридик затлар акчалары хисабына югары белем бирү мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары буенча» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «әйдәүче дәүләт» сүзләрен «федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет бюджет ассигнованиеләре, шулай ук физик һәм юридик затлар акчалары хисабына югары белем бирү мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары буенча» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмалары көндезге уку бүлекләренең укучылар олимпиадалары җиңүчеләреннән һәм бүләкләнүчеләреннән булган студентлары, бердәй дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча 100 әр балл

җыйган гомуми белем бирү оешмаларының чыгарылыш сыйныф укучылары, шулай ук WorldSkills стандартлары буенча һөнәри осталык буенча илкүләм һәм дөнья чемпионатлары җиңүчеләре һәм бүләкләнүчеләре өчен Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре турында нигезләмәдә:

атамасында «дәүләт» сүзен «федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет бюджет ассигнованиеләре, шулай ук физик һәм юридик затлар акчалары хисабына югары белем бирү мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары буенча» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «дәүләт мәгариф оешмалары көндезге уку бүлекләренең» сүзләрен «федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет бюджет ассигнованиеләре, шулай ук физик һәм юридик затлар акчалары хисабына югары белем бирү мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары буенча көндезге уку бүлекләренең» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

2 пунктта «көндезге уку бүлекләренең» сүзләрен «федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет бюджет ассигнованиеләре, шулай ук физик һәм юридик затлар акчалары хисабына югары белем бирү мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары буенча» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Президенты стипендияләре Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә һәр елның 1 сентябреннән югары белем бирү мәгариф оешмасының мәгариф программасы буенча белем алуның тулаем вакытына календарь уку-укыту графигы нигезендә тиешле югары белем бирү мәгариф программасын үзләштерүнең йомгаклары яхшы булган очракта (академик бурычы яисә «канәгатьләнерлек» билгесе булмаса) арадаш яисә йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре буенча билгеләнә.»;

4 пунктта:

беренче абзацка «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына агымдагы елның 15 сентябреннән дә соңга калмыйча җибәрелә торган» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «20 августына кадәр» сүзләрен «1 октябренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Студентка академик отпуск бирелгән, студент югары белем бирү мәгариф оешмасыннан чыгарылган яисә аның олимпиада юнәлешенә туры килми торган башка мәгариф программасына яки әлеге Нигезләмәнең 1 пункты таләпләренә туры килми торган башка югары белем бирү мәгариф оешмасына күчүе (күчерү) яисә арадаш аттестация нәтиҗәләре буенча студентның «канәгатьләнерлек» яисә академик бурычы яки йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре буенча «канәгатьләнерлек» яки «канәгатьләнерлек түгел» билгеләре булган очракта Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән

министрлыгы карары буенча Татарстан Республикасы Президенты стипендиясе түләү туктатыла.»;

икенче абзацта «стипендиясе түләү» сүзләренә кадәр «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Студент академик бурычын тапшырган, ул аттестация нәтиҗәләре буенча «зачет түгел», «канәгатьләнерлек» яки «канәгатьләнерлек түгел» билгеләре алган аттестациядән соңгы арадаш яисә йомгаклау аттестациясен уңышлы тәмамлаган очракта яисә студент академик отпусктан чыкканнан соң Татарстан Республикасы Президенты стипендиясе яңадан түләнә башланмый.».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 26 июль
№ ПУ-497